Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

17.11.2016 ел № 35

Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты хакында

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелүгә бәйле рәвештә, «Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге Советы» Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 29 сентябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә:

1. Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставына түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүне беренче укылышта кабул итәргә:

1.1. 8 статьяны түбәндәге эчтәлекле 15 пунктка өстәргә:

"15) "Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында"2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру.».

1.2. 53 статьяны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

« - "Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында"2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итә.».

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча игълан итәргә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Караталга авылы, күпер ур., 5;

3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк ур., 14;

4) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Караталга авылы, Күпер урамы, 5.

3.«Иске Казиле авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү һәм анда гражданнарның фикер алышуында катнашу турында «муниципаль берәмлек Советы Карары проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (1 нче кушымта).

4. Караталга мәдәният йортында 2016 елның 9 декабрендә 10.00 сәгатьтә «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча ачык тыңлауларны билгеләргә. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 30.11.2006 № 41 карары белән расланган «Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе нигезендә ачык тыңлаулар үткәрергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Иске Казиле авыл җирлеге башлыгы,

Кама Тамагы Иске Казиле авыл җирлеге Советы Рәисе И. Х. Сәгъдиев